**Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе**

# БОЕРЫК

10 сентябрь 2014 ел № 130-од

Казан

Татарстан Республикасының, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен саклау, җитештерү һәм куллану өлкәсендә , административ хокук бозулар буенча беркетмә төзергә һәм административ хокук бозулар буенча башка чаралар кулланырга вәкаләтле дәүләт инспекторлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 19.06.2009 елдан № 401 "хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен саклау, җитештерү һәм куллану өлкәсендә Татасртан Республикасының дәүләт инспекторлары турында"гы һәм 11.09.2013 елдан № 649 "Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, федераль бәядәге аерым саклана торган табигый территорияләрдәге хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен кертмичә, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен саклау, җитештерү һәм куллану өлкәсендә федераль дәүләт тикшерүе булдыра торган, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендәге урындагы затлырның исемлеген раслау турында"гы карарлары белән тәңгәл килеп, **б о е р а м :**

1. Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы Кодексы белән тәңгәл килеп, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе вәкаләте чигендә, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен саклау, җитештерү һәм куллану өлкәсендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган,административ хокук бозулар буенча беркетмә төзергә һәм административ хокук бозулар буенча башка чаралар кулланырга вәкаләтле Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендәге хезмәттәге затларның исемлеген расларга.

2. Исемлектә күрсәтелгән хезмәттәге затларга:

Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы Кодексы белән каралган, административ гамәлият чикләрендә тормышка ашырыла торган, эшләргә куелган таләпләрне һәм тәртипне сакларга;

административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча, әсбапларны рәсмиләштерүне тиешле һәм югары дәрәҗәдә тәэмин итәргә.

3. Гамәлдәге боерыкның үтәлүен тикшерүне үзем артыннан калдырам.

Идарә башлыгы Д.А.Иванов

2014 елның 10 сентябреннән
№ 130-од
Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы
объектларын саклау һәм
файдалану Идарәсе боерыгы
белән расланган

**Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен саклау, җитештерү һәм куллану өлкәсендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган,административ хокук бозулар буенча беркетмә төзергә һәм административ хокук бозулар буенча башка чаралар кулланырга вәкаләтле Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендәге хезмәттәге затларның исемлеге.**

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгының урынбасары

Хайваннар дөньясы объектларын файдалануны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә, рәткә салу, кадастр бүлеге башлыгы

Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлеге башлыгы

Кама арты зонасының хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны саклау, федераль дәүләт тикшерү һәм көйләү бүлегенең район (районара) җитәкчесе

Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны саклау, федераль дәүләт тикшерү һәм көйләү бүлегенең район (районара) башлыклары

Район( районара) хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны саклау, федераль дәүләт тикшерү һәм көйләү бүлекләренең өлкән белгечләре

Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлегенең 1 категорияле белгече